Республика Татарстан
**ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ» САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул.Ахмадиева, д.26, п.Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.09.2020 ел №7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында» 2019 елның 23 апрелендәге 134 номерлы карарына үзгәрешләр кертү буенча ачык тыңлаулар үткәрү хакында»

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, «Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 7 статьясындагы 22 пунктына таянып, Сарман муниципаль районы «Җәлил ш. т. п.» муниципаль берәмлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, халыкның Сарман муниципаль районы «Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү буенча ачык тыңлауларда катнашу хокукларын үтәү максатыннан КАРАР БИРӘМ:

1. 1 нче кушымта нигезендә Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында» 2019 елның 23 апрелендәге 134 номерлы карарына үзгәрешләр кертү буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты һәм Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге - халык алдында тыңлауларны оештыра;

- ачык тыңлауларны үткәрү вакыты - 20.10.2020 ел - 10.00 сәг.;

- үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге администрациясенең утырышлар залы (адресы: Җәлил поселогы, Әхмәдиев ур., 26);

- фикер алышына торган проект буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Җәлил поселогы, Әхмәдиев ур., 26, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты (эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр)

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында» 2019 елның 23 апрелендәге 134 номерлы карарына үзгәрешләр кертү буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча киләсе составта эшче төркем төзергә:

**Эшче төркем рәисе –** Галимова Гөлнара Әзгатовна-Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы;

**Эшче төркем рәисе урынбасары -** Кәримов Рәфыйк Әзһәм улы - Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы;

**Эшче төркем әгъзалары:**

Гайфетдинов Айрат Рифкат улы - Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;

Мөхәммәдиев Айрат Зенфир улы - Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы;

Галләмов Илшат Фикс улы - Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты җитәкчесе»;

Салихов Хәмит Мисбах улы - Сарман муниципаль районы Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы Советы депутаты.

4.Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 18.09.2020 елдан да соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстеннән калдырам.

Сарман муниципаль районы
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлек башлыгы Р. Ә. Кәримов

ПРОЕКТ
Сарман муниципаль районы
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлек башлыгы
14.09.202020 ел № 7 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең 2019 елның 23 апрелендәге 134 номерлы шәһәр тибындагы Җәлил поселогы Советы карары белән расланган генераль планына үзгәрешләр кертү

1. 2 өлешнең 2.8 пунктының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«РФ Су кодексының 65 ст. 15 п. нигезендә һәм 21.02.1992 елның 2395-I номерлы «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 19.1 статьясы нигезендә җир асты байлыкларыннан файдаланучылар углеводород чималын разведкалау һәм чыгару, углеводород чималын геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгару технологияләрен эшләү яки берләштерелгән лицензия буенча авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару, мондый файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару технологияләрен эшләүне, уртак лицензия буенча, углеводород чималын разведкалау һәм чыгару белән шөгыльләнүче җир асты байлыкларыннан файдаланучылар, әлеге закон нигезендә аларга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләре чикләрендә расланган техник проект нигезендә тау токымнары катламнарында иярчен суларны һәм үз җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен файдаланылган суларны җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы билгеләгән тәртиптә урнаштырырга хокуклы.»